МИНИСТЕРСТВО КУЛЬТУРЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Пушкина, д. 66/33, г. Казань, 420015

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЛЫГЫ

Пушкин ур., 66/33нче йорт, Казан ш., 420015

Тел.: (843) 264-74-01, факс: (843) 292-07-26. mkrt@tatar.ru, mincult.tatarstan.ru

**ПРИКАЗ** г.Казань **БОЕРЫК**

**25.12.2017** **1237 од**

Казан шәһәре, Лукницкий урамы, 1 йорт адресы буенча урнашкан җирле (муниципаль) хакимияткә ия мәдәни мирас объекты чикләрен раслау турында

“Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре) турында”гы 2002 елның 25 июнендә кабул ителгән 73-ФЗ номерлы законы, “Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында”гы 2005 елның 1 апрелендә кабул ителгән 60-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, махсус җайга салына торган шәһәр төзелеше эшчәнлеге объектлары буларак, федераль әһәмияткә ия мәдәни мирас объектларын һәм аларның территорияләрен саклауны һәм дәүләт тарафыннан саклап тотуны тәэмин итү максатларында,

БОЕРАМ:

1. Казан шәһәре, Лукницкий урамы, 1 йорт адресы буенча урнашкан җирле (муниципаль) хакимияткә ия мәдәни мирас объекты чикләрен расларга (1нче кушымта).

2. Казан шәһәре, Лукницкий урамы, 1 йорт адресы буенча урнашкан җирле (муниципаль) хакимияткә ия мәдәни мирас объекты чикләреннән файдалану режимын расларга (2нче кушымта).


3. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Министр А. М. Сибагатуллин

Татарстан Республикасы
Мәдәният министрлыгының
25.12.2017 № 1237 од боерыгына
1 нче кушымта

Казан шәһәре, Лукницкий урамы, 1 йорт адресы буенча урнашкан җирле (муниципаль) хакимияткә ия мәдәни мирас объекты **территориясенең чикләре**

Казан шәһәре, Лукницкий урамы, 1 йорт адресы буенча урнашкан “Офицерлар җыены бинасы, XIX гасыр ахыры” җирле (муниципаль) хакимияткә ия мәдәни мирас объекты чикләренең **картасы (схемасы)**




Условные обозначения:

объект культурного наследия

территория объекта культурного наследия

Казан шәһәре, Лукницкий урамы, 1 йорт адресы буенча урнашкан урнашкан “Офицерлар җыены бинасы, XIX гасыр ахыры” җирле (муниципаль) хакимияткә ия мәдәни мирас объекты чикләренең **картографик тасвирламасы**

Казан шәһәре, Лукницкий урамы, 1 йорт адресы буенча урнашкан урнашкан “Офицерлар җыены бинасы, XIX гасыр ахыры” җирле (муниципаль) хакимияткә ия мәдәни мирас объекты чикләре түбәндәгечә уза:

**Төньяк өлеш**:күрше бинага параллель уза (н.1-2), койма буйлап уза (н.2-3)

**Көнчыгыш өлеш**: бинаны әйләнеп үтә (н. 4-7), почмакка кадәр бина буйлап үтә, ә аннары койма буйлап (н. 7-8).

**Көньяк өлеш:** койма буйлап үтә (н. 8-9).

**Көнбатыш өлеш:** төньяк юнәлештә үтә (н. 9-10), көнчыгыш юнәлештә үтә (н. 10-11), төньяк юнәлештә үтә (н. 11-12), көнбатыш юнәлештә үтә (н.12-13), төньяк юнәлештә үтә (н. 13-1)

Казан шәһәре, Лукницкий урамы, 1 йорт адресы буенча урнашкан урнашкан “Офицерлар җыены бинасы, XIX гасыр ахыры” җирле (муниципаль) хакимияткә ия мәдәни мирас объекты чикләренең **борылыш нокталары таблицасы**

| Нокта № | Җирле координаталар системасында нокталарның координатлары (МСК-16) | | 1894 елгы бөтендөнья геодезик координаталар системасында нокталарның координаталары (WGS-84) | |
|---|---|---|---|---|
| | X | Y | Төньяк киңлек B | Көнчыгыш озынлык L |
| **1** | 478543.85 | 1302027.67 | 55°48'51.106" | 49°3'50.512" |
| **2** | 478540.65 | 1302066.98 | 55°48'51.002" | 49°3'52.769" |
| **3** | 478514.25 | 1302063.42 | 55°48'50.148" | 49°3'52.564" |
| **4** | 478495.28 | 1302061.20 | 55°48'49.535" | 49°3'52.436" |
| **5** | 478494.90 | 1302064.20 | 55°48'49.523" | 49°3'52.608" |
| **6** | 478487.96 | 1302063.29 | 55°48'49.298" | 49°3'52.556" |
| **7** | 478488.34 | 1302060.31 | 55°48'49.311" | 49°3'52.385" |
| **8** | 478456.40 | 1302056.23 | 55°48'48.278" | 49°3'52.149" |
| **9** | 478461.88 | 1302014.27 | 55°48'48.456" | 49°3'49.740" |
| **10** | 478493.70 | 1302018.30 | 55°48'49.485" | 49°3'49.972" |
| **11** | 478492.94 | 1302024.26 | 55°48'49.460" | 49°3'50.315" |
| **12** | 478520.41 | 1302027.78 | 55°48'50.348" | 49°3'50.517" |
| **13** | 478520.79 | 1302024.80 | 55°48'50.360" | 49°3'50.346" |

Татарстан Республикасы
Мәдәният министрлыгының
25.12.2017 № 1237 од боерыгына
2 нче кушымта

Казан шәһәре, Лукницкий урамы, 1 йорт адресы буенча урнашкан урнашкан “Офицерлар җыены бинасы, XIX гасыр ахыры” җирле (муниципаль) хакимияткә ия мәдәни мирас объекты территориясеннән **файдалану режимы**

Җирле (муниципаль) мәдәни мирас объектының территориясе чикләрендә түбәндәгеләр **рөхсәт ителә:**

мәдәни мирас объектының физик яктан саклануын тәэмин итүгә юнәлтелгән саклау эшләре үткәрү, шул исәптән, консервацияләү, ремонтлау, реставрацияләү һәм заманча файдалануга яраклаштыру;

мәдәни мирас объектларының бөтенлегенә зыян салмаган һәм мәдәни мирас объектын бүгенге шартларда кулланылуын тәэмин итү мөмкинлеге биргән хуҗалык эшчәнлеге алып бару;

Алда аталган эшләр мәдәни мирасны саклауга вәкаләтле орган тарафыннан килештерелгән мәдәни мирас объектларын саклап калу буенча проект документларын әзерләү һәм эшләр башкару буенча йөкләмәләр, күрсәтелгән эшләрнең башкарылуын мәдәни мирас объектын саклауга вәкаләтле орган контрольдә тоткан очракта – проект документлары нигезендә мәдәни мирас объектын саклауга вәкаләтле орган тарафыннан мәдәни мирас объектын саклау эшләре үткәрергә язмача рөхсәт кәгазе нигезендә башкарыла.

булган капиталь төзелеш объектларын, шулай ук җир кишәрлекләрен (капиталь төзелеш объектлары сафка бастырмыйча һәм вакытлы корылмалар урнаштырмыйча) рөхсәт ителгән куллану төрләре нигезендә файдалану (рөхсәт ителгән төрләрнең кодлары Россия Федерациясе Икътисади үсеш министрлыгының 2014 елның 1 сентябрендә кабул ителгән “Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторын раслау турында”гы 540 нчы боерыгы нигезендә күрсәтелгән):
- коммуналь хезмәт күрсәтү (код 3.1);
- социаль хезмәт күрсәтү (код 3.2);
- мәгариф һәм белем бирү (код 3.5);
- мәдәни үсеш (код 3.6);
- иҗтимагый идарә (код 3.8);
- фәнни эшчәнлекне тәэмин итү (код 3.9);
- җәмәгать туклануы (код 4.6);

мәдәни мирас объектының бөтенлеген боза торган вакытлы корылмаларны һәм объектларны сүтү;

булган инженер инфраструктурасы объектларын капиталь ремонтлау (тышкы су белән тәэмин итү челтәре, канализацияләр, җылылык, газ, электр белән тәэмин итү, телефон үткәрү);

мәдәни мирас объектын саклап калу, файдалану һәм популярлаштыру өчен территорияне төзекләндерү:

мәйданчыкларга, якын килү һәм транспорт узу урыннарына традицион материаллар (таш, гранит һәм табигый материалга охшаш башка материаллар) түшәү;

тарихи мохит элементлары характеристикаларына җавап бирә торган аерым урнаштырылган яктырту җайланмаларыннан файдалану; агачларның кыйммәтле төрләрен саклап калу);

тарихи-архив тикшеренүләре нигезендә махсус эшләнгән проектлар буенча киосклар, өслекләр, кече архитектур формалар урнаштыру;

мәдәни мирас объектлары фасадларында мәгълүмати язулар һәм билгеләмәләрне мәдәни мирас объектының беренче катыннан да югары күтәрмичә урнаштыру;

алда аталган мәгълүмати конструкцияләрнең биеклеге фриз биеклегенең 2/3сеннән артмаска тиеш. Аркалы тәрәзәләр булганда катларның тәрәзәләре арасында урнашкан конструкцияләрнең биеклеге ½ гә кими. Мәгълүмати конструкцияләрнең киңлеге дивар киңлегенең 2/3сеннән артмаска тиеш.

археологик белешмәләр булган очракта территориянең директив дәрәҗәсен түбәнәйтү, ишегалды территориясен вертикаль планлаштыру.

Җирле (муниципаль) мәдәни мирас объектының территориясе чикләрендә түбәндәгеләр **тыела:**

Мәдәни мирас объектының территориясе чикләрендә түбәндәгеләр **тыела:**

мәдәни мирас объектларын яки аерым элементларын саклауга, мәдәни мирас объектының тарихи шәһәр төзелеш тирәлеген саклауга бәйле булмаган җир, төзелеш, мелиорация белән бәйле һәм башка эшләр башкару;

капиталь төзелеш объектлары сафка бастыру һәм ядкарь территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектларының күләм-пространство характеристикасын арттыру;

мәдәни мирас объекты фасадына һәм түбәсенә кондиционерлар, эре габаритлы антенналар һәм инженерлык җиһазларының башка элементларын урнаштыру;

тышкы реклама чараларын урнаштыру;

инженерлык инфараструктурасын (суүткәргечнең тышкы челтәре, канализация, җылылык, газ һәм электр белән тәэмин итү, телефонлаштыру) җир өстеннән үткәрү;

мәдәни мирас объектына һәм аның әйләнә-тирәсендәге корылмаларга динамик тәэсир итүче технологияләрдән файдалану;

мәдәни мирас объекты территорияләрен төрле көнкүреш калдыклары белән чүпләү;

парковкакалар төзү.